СОВЕТ
ШУШМАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Габделхая Каримова, д.1б, с.Шушмабаш,
Арский муниципальный район,422036

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШУШМАБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Габделхәй Кәримов урамы, 1б йорт, Шушмабаш авылы,
Арча муниципаль районы,422036

Тел. (84366) 93-1-24 факс (84366) 93-1-24. E-mail: Shush.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы**

**КАРАРЫ**

**22 март 2024 ел** **№1**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлегенең Ишнарат авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында" 2023 елның 16 ноябрендәге 5 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлегенең Ишнарат авылында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль Шушмабаш авыл җирлеге Уставының 25 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы Карар бирде:

1. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлегенең Ишнарат авылында гражданнар жыены нәтижәләре турында» 2023 елның 16 ноябрендәге 5 номерлы карарына үзгәрешләр керту турында» мәсьәләсе буенча Ишнарат авылы, Җиңү урамы, 9а йорты адресы буенча 2024 елның 5 нче апреленә 08 сәгать 00 минутта халык җыенын билгеләргә.

2. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлегенен Ишнарат авылында гражданнар жыены нэтижэлэре турында» 2023 елның 16 ноябрендәге 5 номерлы карарында гражданнар жыены соравын яңа редакциядэ бәян итәргә:

«Сез 2024 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлегенең Ишнарат авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, 70 яшьтән узган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- янгынга каршы резервуарлар (янгынга каршы су җыю урыннарын), янгын пирслары ясау, ремонтлау (Ишнарат авылына янгын савыты сатып алу һәм Җиңү урамы, 9 нчы йорт янына урнаштыру);

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәсен тәэмин итү һәм

электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (Ишнарат авылында урам яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән 10 данә яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру)?
Аерым мәсьәләләр буенча экономия булганда, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны җыенда каралган башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга.

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»»

3. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлегенең Ишнарат авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында" 2023 елның 16 ноябрендәге 5 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

4. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Ишнарат авылы, Җиңү урамы, 11а адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Шушмабаш авыл җирлеге башлыгы В.В.Сәгыйтов

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН * АРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН * ОГРН1121690000210 * МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «ШУШМАБАШСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
СОВЕТ ШУШМАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН1609012678